**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2023 ел, 25 сентябрь №208

**Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районына керүче: Апас шәһәр җирлеге, Әлмәндәр авыл җирлеге, Бакырчы авыл җирлеге, Биеш авыл җирлеге, Олы Болгаер авыл җирлеге, Зур Күккүз авыл җирлеге, Болын-Балыкчы авыл җирлеге, Югары Аккуҗа авыл җирлеге, Югары Ындырчы авыл җирлеге, Дәвеш авыл җирлеге, Ишеево авыл җирлеге, Каратун авыл җирлеге, Кызылтау авыл җирлеге, Коштауылы авыл җирлеге, Сатмыш авыл җирлеге, Урта Балтай авыл җирлеге, Иске Йомралы авыл җирлеге, Табар Черкене авыл җирлеге,Тутай авыл җирлеге, Чирмешән авыл җирлеге, Чүри-Бураш авыл җирлеге, Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советларына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына югарыда күрсәтелгән җирлекләрнең башкарма комитетларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү;

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслашкан хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;

-җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген хезмәт күрсәтүләр сыйфатына карата таләпләрне раслау;

-җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау;

-ир яисә хатын, якын туганнары, башка туганнары йә үлгән кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә аларның күмү мөмкинлеге булмаганда, үлгән (һәлак булган) мәетне күмү өчен хезмәт күрсәтүләрнең бәясен раслау, шулай ук, үз өстенә күмүне башкару бурычын алган башка затлар булмаганда, эчке эшләр органнары шәхесне билгеләгәннән соң өйдә, урамда яисә башка урында үлгәнне җирләү хезмәте күрсәтүләрнең бәясен раслау;

-Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе билгеләнмәгән үлгән (һәлак булучыларны) җирләү хезмәтләре бәясен раслау.

2. Апас шәһәр җирлеге, Әлмәндәр авыл җирлеге, Бакырчы авыл җирлеге, Биеш авыл җирлеге, Олы Болгаер авыл җирлеге, Зур Күккүз авыл җирлеге, Болын-Балыкчы авыл җирлеге, Югары Аккуҗа авыл җирлеге, Югары Ындырчы авыл җирлеге, Дәвеш авыл җирлеге, Ишеево авыл җирлеге, Каратун авыл җирлеге, Кызылтау авыл җирлеге, Коштаулы авыл җирлеге, Сатмыш авыл җирлеге, Урта Балтай авыл җирлеге, Иске Йомралы авыл җирлеге, Табар-Черкене авыл җирлеге,Тутай авыл җирлеге, Чирмешән авыл җирлеге, Чүри-Бураш авыл җирлеге, Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советлары тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул ителсә,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына:

Шәһәр тибындагы Апас бистәсе, Әлмәндәр авыл җирлеге, Бакырчы авыл җирлеге, Биеш авыл җирлеге, Олы Болгаер авыл җирлеге, Зур Күккүз авыл җирлеге, Болын-Балыкчы авыл җирлеге, Югары Аккуҗа авыл җирлеге, Югары Ындырчы авыл җирлеге, Дәвеш авыл җирлеге, Ишеево авыл җирлеге, Каратун авыл җирлеге, Кызылтау авыл җирлеге, Коштаулы авыл җирлеге, Сатмыш авыл җирлеге, Урта Балтай авыл җирлеге,

Иске Йомралы авыл җирлеге, Табар Черкене авыл җирлеге, Тутай авыл җирлеге, Чирмешән авыл җирлеге, Чүри-Бураш авыл җирлеге, Шәмбалыкчы авыл җирлегенең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2023елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына бюджеты турындагы карарга бюджет законнары нигезендә үзгәрешләр кертү турындагы карарның проектын эшләргә һәм тикшерүгә тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга,шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

**Апас**
**муниципаль район Башлыгы урынбасары –**
**Апас муниципаль районы**
**Советы рәисе урынбасары** **Л.Т. Хантимиров**